# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм "Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2011 елның 28 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

Чүпрәле муниципаль районы составына керә торган "Алешкин-Саплык авыл җирлеге" һәм "Иске Чүпрәле авыл җирлеге" муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

"Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" 2005 елның 31 гыйнварындагы 21-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (V өлеш); 2010, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында" Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

# "Чүпрәле муниципаль районы" муниципаль берәмлеге составына керүче муниципаль берәмлекләрнең чикләре **карта-схемасы**




Шартлы билгеләр

- республика чиге
- муниципаль район чиге
- 10 - тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 - жирлекләрнең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- жирлек үзәге

Муниципаль районның чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 25(10)-26(12) | - Чуаш Республикасы |
| 26(12)-27(13) | - Ульяновск өлкәсе |
| 27(13)-33(6) | - Чуаш Республикасы |
| 33(6)-37(5) | - Буа муниципаль районы |
| 37(5)-25(10) | - Ульяновск өлкәсе |

"Чүпрәле муниципаль районы"
муниципаль берәмлегә составына керүче
авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Алешкин-Саплык авыл җирлеге |
| 2 | Зур Аксу авыл җирлеге |
| 3 | Зур Чынлы авыл җирлеге |
| 4 | Городище авыл җирлеге |
| 5 | Звезда авыл җирлеге |
| 6 | Кече Чынлы авыл җирлеге |
| 7 | Марс авыл җирлеге |
| 8 | Матак авыл җирлеге |
| 9 | Түбән Чәке авыл җирлеге |
| 10 | Яңа Борындык авыл җирлеге |
| 11 | Яңа Әлмәле авыл җирлеге |
| 12 | Яңа Ишле авыл җирлеге |
| 13 | Үби авыл җирлеге |
| 14 | Иске Чүпрәле авыл җирлеге |
| 15 | Иске Кәкерле авыл җирлеге |
| 16 | Иске Чокалы авыл җирлеге |
| 17 | Иске Шәйморза авыл җирлеге |
| 18 | Чуаш Чүпрәлесе авыл җирлеге |
| 19 | Шланга авыл җирлеге |

";

2) 3 нче кушымтаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Алешкин-Саплык авыл җирлеге чиге Иске Чүпрәле авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, "Казан – Ульяновск" – Иске Чүпрәле автомобиль юлын кисеп үтеп, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 550 м сынык сызык белән төньяк-көнбатышка таба,

800 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырланган урыннарның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кече Чынлы елгасына кадәр, 4,4 км елга агымы буенча аска таба Алешкин-Саплык, Яңа Ишле һәм Иске Чүпрәле авыл җирлекләре чикләре тоташкан урында Татар Саплыгы авылыннан 1,5 км төньяк-көнбатышта урнашкан 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.";

3) 16 нчы кушымтаның сигезенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Иске Чүпрәле авыл җирлеге чиге Алешкин-Саплык авыл җирлеге белән чиктәш җирдә 19 нчы тоташу ноктасыннан алып авыл хуҗалыгы җирләре буйлап 2,0 км төньяк-көнбатышка таба, 2,2 км төньяк-көнчыгышка таба, кибеп баручы инешне кисеп үтеп, 200 м төньяк-көнбатышка таба, 150 м урман полосасының төньяк-көнчыгыш чиге буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 250 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 200 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 150 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 100 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, "Казан – Ульяновск" – Иске Чүпрәле автомобиль юлын кисеп үтеп, 800 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап, 20 м төньяк-көнчыгышка таба урман полосасының төньяк-көнбатыш чиге буйлап, 100 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап һәм 550 м сынык сызык белән төньяк-көнчыгышка таба, 800 м төньяк-көнчыгышка таба, 300 м урман полосасының көньяк-көнбатыш чиге буйлап төньяк-көнбатышка таба, 350 м авыл хуҗалыгы җирләре буйлап, 150 м чокырланган урыннарның төньяк-көнчыгыш чиге буйлап Кече Чынлы елгасына кадәр, 4,4 км бу елга агымы буенча аска таба 13 нче тоташу ноктасына кадәр бара.".

**3 статья**


Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2011 елның 19 мае
№ 25-ТРЗ

«Аерым муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Чүпрәле муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына кушымта

# Чикләре әлеге Закон нигезендә үзгәртелә торган муниципаль берәмлекләр территорияләренең **карта-схемасы**




## Шартлы билгеләр

- муниципаль берәмлекләр чикләре

А-Б - Алешкин-Саплык авыл җирлеге һәм Иске Чүпрәле авыл җирлеге берәмлекләренең чиктәш чиге

- торак пункт

- Чүпрәле муниципаль районының Алешкин-Саплык авыл җирлеге территориясе составына керә торган Чүпрәле муниципаль районының Иске Чүпрәле авыл җирлеге территориясе